**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

№15/1 «27» август 2026 ел

**Тукай муниципаль районы «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 14 февралендәге 1/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге уставына таянып, Калмия авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы «Калмия авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 14 февралендәге 1/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының 25.05.2020 ел № 2/1; 19.05.2022 ел № 14/3; 29.06.2023 ел № 25/1; 01.07.2024 ел № 45/2; 20.03.2025 ел № 57/1; 10.12.2025 ел № 4/1 карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15.1 нче пунктын яңа редакциядә түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«15.1. Муниципаль хезмәт вазифасын биләүне дәгъвалаучы граждан, муниципаль хезмәткәр эшкә алучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне әлеге Федераль законда каралган нигездә тапшырыла. Күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла».

1.2. 15.2 нче пунктын яңа редакциядә түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«15.2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазифасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм формада тапшырырга тиеш».

1.3. 15.4нче пунктын яңа редакциядә түбәндәге эчтәлекне бәян итәргә:

«15.4. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге бүлек нигезендә тапшырыла торган белешмәләр, әгәр федераль законнар белән дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.».

1.4. 15.5 нче пунктын яңа редакциядә түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«15.5. Муниципаль хезмәткәргә әлеге бүлек нигезендә тапшырыла торган бирелгән белешмәләрдән муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ

булмаган балаларының түләү сәләтен билгеләү өчен, дини яисә башка иҗтимагый берләшмәләр, башка оешмалар, шулай ук физик затлар фондларына турыдан-туры яисә читләтелгән рәвештә иганәләр (взнослар)җыю өчен файдалану рөхсәт ителми».

1.5. 15.6 нче пунктын яңа редакциядә түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«15.6. Әлеге бүлек нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне ачуда яки әлеге белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда куллануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар».

1.6. 15.7 нче пунктын яңа редакциядә түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«15.7. Муниципаль хезмәткәр тарафынан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затлар чыгымнарының туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында белешмәләрне тапшырмау, мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булган, йә белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыру, федералҗ законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булган очракта»;

1.7. 15.12 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

1.8. 17.2.1 пунктының 10 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«10) 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;»

.

2.Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советының 08.05.2026 ел, №10/1«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл жирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезламәгә узгәрешләр кертү хакында» 14.02.2019 ел, №1/3 карарын уз кечен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм махсус стендларда, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында tukay.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Калмия авыл муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Р. Р. Харрасова